КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 12 апрель г.Казань № 452

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт программаларын һәм ведомство максатчан программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм аларның нәти-җәлелеген бәяләү тәртибен һәм Татарстан Республикасы дәүләт программалары исемлеген раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1199 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлеген һәм Татарстан Республикасының дәүләт программаларын, ведомство максатчан программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1199 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 26 апрель, 282 нче; 2013 ел, 29 апрель, 294 нче; 2013 ел, 29 июнь, 454 нче; 2013 ел, 19 июль, 507 нче; 2013 ел, 24 октябрь, 789 нчы; 2013 ел, 31 декабрь, 1110 нчы; 2014 ел, 15 март, 157 нче; 2014 ел, 14 апрель, 242 нче; 2014 ел, 11 июнь, 405 нче; 2014 ел, 9 июль, 475 нче; 2015 ел, 6 май, 326 нчы; 2015 ел, 16 май, 346 нчы; 2015 ел, 22 июль, 532 нче; 2016 ел, 17 февраль, 101 нче; 2016 ел, 27 апрель, 252 нче; 2016 ел, 12 май, 298 нче; 2016 ел, 10 июнь, 396 нчы; 2016 ел, 12 октябрь, 740 нчы; 2016 ел, 26 декабрь, 989 нчы; 2017 ел, 20 апрель, 232 нче; 2017 ел, 13 май, 281 нче; 2017 ел, 30 октябрь, 821 нче; 2017 ел, 30 октябрь, 823 нче; 2017 ел, 21 ноябрь, 895 нче; 2017 ел, 28 ноябрь, 920 нче; 2017 ел, 29 декабрь, 1117 нче; 2018 ел, 11 июнь, 458 нче; 2018 ел, 16 ноябрь, 1002 нче; 2019 ел, 5 март, 156 нчы; 2019 ел, 26 апрель, 344 нче; 2019 ел, 27 июнь, 517 нче; 2019 ел, 13 сентябрь, 830 нчы; 2019 ел, 11 декабрь, 1136 нчы; 2021 ел, 24 май, 362 нче, 2021 ел, 18 октябрь, 980 нчы, 2021 ел, 3 ноябрь, 1043 нче, 2022 ел, 7 июнь, 538 нче, 2022 ел, 5 август, 764 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт программаларын һәм ведомство максатчан программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибендә:

1.2 пунктның сигезенче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе» сүзләренә алмаштырырга;

1.6 пунктның унынчы абзацында «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе» сүзләренә, «Татарстан Республикасы Президенты карарлары» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе карарлары» сүзләренә алмаштырырга;

3.1 пунктта «Татарстан Республикасы Президентының» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең» сүзләренә алмаштырырга;

7.6.2 пунктта «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт программалары исемлегендә:

3 пунктның дүртенче графасында «Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге (килешү буенча)» сүзләрен «Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге (килешү буенча)» сүзләренә алмаштырырга;

19 пунктта:

өченче графада «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәткәрләре эшләре департаменты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче графада «Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты (килешү буенча)» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты (килешү буенча)» сүзләренә алмаштырырга;

20 пунктның дүртенче графасында «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәткәрләре эшләре департаменты (килешү буенча)» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты (килешү буенча)» сүзләренә алмаштырырга;

27 пунктның дүртенче графасында «Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре буенча идарәсе (килешү буенча); Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты (килешү буенча); Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил (килешү буенча)» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре буенча идарәсе (килешү буенча); Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты (килешү буенча); Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил - Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчесе» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин